РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» март 2021 г. г. Альметьевск № 40

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 244 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 244 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 16 декабрендәге 343 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып),түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның «Район Башкарма комитеты вәкаләтләре» 2 бүлегендә түбәндәге карарга:

1.1. 2.2 пунктта:

1.1.1. 3 пунктчаның 12 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыра һәм территориянең карта-планын раслый;»;

1.1.2. 8 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 22 абзац өстәргә:

«- шәһәр һәм авыл торак пунктларыннан читтәге муниципаль район чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итә;»;

1.1.3. 11 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 17, 18, 19 абзацлар өстәргә:

«- участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр әлеге вазыйфаны биләгән вакытка торак урыны бирә;

- исерек, наркотик яисә башка токсик халәттәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын күрә;

- муниципаль янгын сагын төзи;»;

1.1.4. 11 пунктчаның 17 абзацын 20 абзац дип санарга.

Заказ № 2625

1.2. 2.3 пунктта:

1.2.1. 3 пунктчаның 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- комплекслы кадастр эшләрен башкаруда федераль закон нигезендә катнаша;»;

1.2.2. 3 пунктчага түбәндәге эчтәлекле 12 абзац өстәргә:

«- җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар күрә һәм үткәрә, күчемсез мелкәтнең Бердәм дәүләт реестрына кертү өчен күчемсез мөлкәт объектларының хокукка ия булучылары турында белешмәләр җибәрә.».

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар, әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 декабрендәге 445-ФЗ номерлы Федераль законның 1 нче кушымтасы 2 бүлеге 2.3 пункты 3 пунктчасы 10 нче абзацы һәм 2.2 пункты 3 пунктчасы 12 абзацында каралган хокук мөнәсәбәтләренә карата 2021 елның 23 мартыннан, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 518-ФЗ номерлы Федераль законның 1 нче кушымтасы 2 бүлеге 2.3 пункты 3 пунктычасы 12 абзацында каралган каралган хокук мөнәсәбәтләренә карата 2021 елның 29 июненнән, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге эшчәнлекне камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 декабрендәге 454 номерлы Федераль законның 1 нче кушымтасы 2 бүлеге 2.2 пункты 11 пунктчасы 19 абзацы һәм 8 пунктчасы 22 абзацы өлешендә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.)

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов